# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ БОЛГАЕР АВЫЛЫ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАРЫ

**2018 ел 16 ноябрь** **№ 81**

**“Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Олы Болгаер авылы җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре вазыйфаи зат буларак, җирле үзидарә органнарына сайланган, үз вәкаләтләрен даими гамәлгә ашыручы депутатларның хезмәте өчен түләү турында” 2018 елның 5 апреленда кабул ителгән 55 номерлы карарына үзгәртүләр кертү турында**

"Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән расланган җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү хакында" карарына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 182 нче Карарына үзгәрешләр кертү хакында”гы 2018 елның 17 октябрендәге 940 нчы Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Олы Болгаер авылы җирлеге Советы карар итте:

1. 2018 елның 5 апрелендa кабул ителгән 55 номерлы “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Олы Болгаер авылы җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләре вазыйфаи зат буларак, җирле үзидарә органнарына сайланган, үз вәкаләтләрен даими гамәлгә ашыручы депутатларның хезмәте өчен түләү турында” Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Олы Болгаер авылы җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәртүләр кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 6.1 пункт өстәргә:

«6.1.Җирлек башлыгына айлык акчалата бүләк һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр түләнә торган түләүдән тыш, муниципаль хокукый актлар нигезендә айлык акчалата бүләк, тиешле елларны эшләгән өчен айлык өстәмә түләү һәм премияләр дә түләнә ала.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Айлык акчалата бүләкләү өлешендә җирлек Башлыгының хезмәт өчен түләү чыгымнары күләме елына 6,72 акчалата бүләк тәшкил итүче нормативтан артып китә алмый.».

2.Әлеге карар 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар Рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Олы Болгаер авылы**
**җирлеге башлыгы** **Сайфуллина З.И.**